РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноября 2023 г. г. Альметьевск № 257

«2023 елга Әлмәт муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022 елның 12 декабрендәге 178 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционер җәмгыяте мөрәҗәгатен исәпкә алып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2023 елга Әлмәт муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022 елның 12 декабрендәге 178 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына (2023 елның 11 сентябрендәге 243 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасында 12 - 49 пунктларында күрсәтелгән «Коммуналь хуҗалык объектлары - кайнар су белән тәэмин итү һәм җылылык белән тәэмин итү челтәрләре» бүлегендә муниципаль мөлкәтне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясенең «torgi.gov.ru» рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов